**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЧУАШ БОРНАЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**КАРАРЫ**

2020 елның 10 июне 3№

2020 елга Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
Чуаш Борнае авыл җирлеге милкендә булган
мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фараз
планы (программасы) турында

2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 50 һәм 51 статьялары, 85 статьясындагы 8 пунктның 4 пунктчасы, 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»гы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.2020 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фараз планын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына 2020 елда Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фараз планын үтәү өчен кирәкле әзерлек чараларын гамәлгә ашыру максатларында мөрәҗәгать итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми www.alkeevskiy.tatarstan.ru сайтында һәм «Интернет» челтәрендәге Россия Федерациясенең рәсми www.torgi.gov.ru сайтында урнаштырырга.http://www.alkeevskiy.tatarstan.ru/

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының бюджет, салымнар һәм финанслар, җирле җыемнар, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе, Әлки муниципаль районы
Чуаш Борнае авыл җирлеге башлыгы: И Г. Зарипов

**2020 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы " Чуаш Борнае авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтне хосусыйлаштыруның Фараз планы ( программасы)**

## 1Бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2020 елга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Чуаш Борнае авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендә булган мөлкәтне (алга таба-муниципаль милек) хосусыйлаштыруның Фараз планы (программасы) 2001елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»гы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Чуаш Борнае авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләнде.

1.2. 2020 елда муниципаль милекне хосусыйлаштыру муниципаль милек белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, күчемсез милек объектларын тотуга инвестицияләр җәлеп итүгә, муниципаль милекне сатудан бюджет дефицитын каплау чыганакларын булдыруга юнәлдерелгән.

1.3. 2001елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында»гы Федераль закон нигезендә муниципаль милекне хосусыйлаштыруны аукционда сату юлы белән башкару күздә тотыла.

## 2 Бүлек. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек

2.1. 2020 елда Әлки муниципаль районы бюджетыннан финансланучы муниципаль казнадагы һәм оешмалар файдаланмаган муниципаль милек хосусыйлаштырылырга тиеш.

2.2.Хосусыйлаштырырга планлаштырылган муниципаль милек исемлеге:

| т/б № | Мөлкәтнең атамасы һәм характеристикасы | Адрес (урнашу урыны) | Файдалануга тапшыру елы, (чыгару елы) | Хосусыйлаштыруның фаразланган вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Автотранспорт чарасы FIAT-178 CYNIA ALBEA идентификация номеры (VIN) XU317800BZ137045 җиңел | Татарстан Республикасы, Әлки муниципаль районы, Татар Борнае авылы, Мәктәп ур., 16 й. | 2011 | 3,4 квартал |

## 3 Бүлек Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруны мәгълүмати тәэмин итү

3.1. Муниципаль милекне хосусыйлаштыру турындагы мәгълүматны оператив рәвештә бирү һәм киңрәк реклама белән тәэмин итү максатыннан Чуаш Борнае авыл җирлеге башкарма комитеты әлеге фараз планын үтәү барышында, рәсми мәгълүмат чыганакларыннан тыш, бүтән массакүләм мәгълүмат чаралары хезмәтеннән дә файдаланырга хокуклы.